ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.12.2024 ел Баулы шәһәре №181

Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 65 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру максатларында, инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларга һәм аларның гаилә әгъзаларына ярдәм мәсьәләләре буенча региональ ведомствоара комиссиянең Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л. Р. Фазлыева тарафыннан расланган, 2024 елның 3 декабрендәге ЛФ-12-345 номерлы утырыш беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 12 апрелендәге 65 номерлы карары белән расланган, Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак фонды, шулай ук хосусый торак фонды составына керүче инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда, аларны инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып җайлаштыру максатларында, инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча комиссия составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

комиссия составына «Ватанны саклаучылар» дәүләт фондының Татарстан Республикасы буенча филиалының Баулы муниципаль районындагы вәкиллегенең социаль координаторы Лендяева Марта Ильдар кызын кертергә (килешү буенча).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров